Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш авылында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 23 ноябре №1

"Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә,

"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыру турында" 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктындагы халык җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда һәр балигъ булган, теркәлгән урыны буенча

Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы түләтүне кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Акбаш авылының Мәктәп урамы буенча юлны асфальтлауга;
-Акбаш авылындагы су челтәрләрен һәм чишмәләрен реонтлау һәм сафта тотуга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Акбаш авыл җирлегенең рәсми стендларында, http://pravo.tatarstan рәсми мәгълүмат хокукый порталында, Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: Л.Р.Сөнәгатуллина